СОВЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с.Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕҖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)53-2-36, факс (84366)53-2-36. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

**Сеҗе авыл җирлеге**
**КАРАР**

**05 май 2021ел**
**№ 25**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл Советының 2015 елның 03 ноябрендәге 9 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (29.11.2018 № 78, 16.10.2019 № 107 карарлар редакциясендә)**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Сеҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына яраклаштырып, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл Советының 2015 елның 03 ноябрендәге 9 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (29.11.2018 №78, 16.10.2019 № 107 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның 1.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3.1 пунктча өстәргә:

«3.1. Физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән түбәндәгеләрне азат итәргә:

3.1.1. 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарны;

3.1.2. Әлеге пунктның 3.1.1. пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балаларын.

Салым ташламасы түбәндәге төр салым салу объектларына карата бирелә:

- фатир, фатирның бер өлеше яисә бүлмә;
-торак йорт яисә торак йортның бер өлеше;
-гараж яки мәйданы 30 кв метрдан да артык булмаган машина урыны.

Салым ташламасы, салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына бәйсез рәвештә, салым түләүченең теләге белән гаиләгә туры килә торган һәр салым салу объектына карата бирелә.

Салым ташламасы Арча шәһәре территориясендә даими яшәүче салым түләүчеләргә салым түләүче тарафыннан салым түләүче милкендәге һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган салым салу объектына карата булган салым суммасы күләмендә бирелә.

Салым ташламаларына хокукы булган физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турында гаризаны үз сайлавы буенча бирә, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукынраслый торган документларны тапшырырга хокуклы.

Салым ташламасына хокукны раслаучы документлар түбәндәгеләр:
-әлеге салым буенча салым түләүче дип танылган физик затның шәхесен таныклаучы документ;
- аның исеменә бирелгән күпбалалы гаилә таныклыгы.

Салым ташламасы бирелә торган салым салуның сайланган объектлары турында хәбәрнамә салым түләүче тарафыннан әлеге объектларга карата салым ташламасы кулланыла торган салым чоры булып торган елның 1 ноябренә кадәр салым органына тапшырыла».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы сайтында яисә «Арча хәбәрләре» газетасында рәсми басылып чыккан көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча даими эшләүче комиссиягә йөкләргә.

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы Хамидуллин Р.В.